## ГӨЛӘПЛӘР КЕРФЕГЕ

Офыкта кып-кызыл бөркет канат җәйгән. Тартылган җәянең кереше сыман, һава зыңлап тора. Бөркетнең җем-җем итеп торган каурыйлары менә-менә җиһанга таралыр сыман.

Сусыл үләннәрне ерып, урманга кереп барам. Кызыл бөркет иңбашыма килеп куна, канат очы исә күземә орынып ала.

Тамагыма төер утыра. Тезләнеп, күк гөмбәзенә кулны сузасым, күкрәк куышлыгында яралган гади дә, бергә тезелгәч сәер дә яңгыраган сүзләрне дөньяга кычкырасым килә. Минем өйрәнчек арбаулар һәрвакыт табигать могҗизаларына эндәшү белән башлана иде: “Яңгыр, яңгыр!” яисә “Җил, кил монда...”

Бу самими юллар телемне ачкан сүзләрдән тезелә. Мин әле әдәби телнең барлыгын белмим. Цык-цык... Гүя һун бабаларыбыз менгән атларның тояклары Рум юлларының ташларына бәрелә, Дәште Кыпчак ханнарының камчысы цыкылдап шартлый.

Якты аланга килеп чыккач, җиләк җыеп йөрүче урман кызы миңа кул болгый. Мин аңа таба йөгерәм, колагына назлы сүзләр пышылдыйсым, кояшның учымда калган эзен күрсәтеп, сөенче аласым килә. Аның да коңгырт күзендә миңа гына ишеттерәсе сер күләгәсе бар сыман.

Бер-берсен этә-төртә сүзләр аңа таба ашыга. Аларны бер тезмәгә салырга сабырлыгым җитми. Сандугачка ничек сокланмыйсың! Әнә ул кайсыдыр куактан сак кына аваз бирде, аннары онытылып сайрый башлады. Сандугачның тылсымлы сулышы кызның бәрхеттәй керфегендә тибрәнде.

Колагымда — сандугач тавышы, күз алдымда — урман кызы...

Мин әле шигырьнең вәзенен дә чамаламыйм. Шигырь сабыйлык туфрагында ботаклы-чатаклы куак булып үсеп чыга. Куакларны ерып, үз сукмагымны эзлим, гөләпләрнең керфегенә килеп төртеләм.

Әдәбиятның киң, сикәлтәле юлына килеп чыккач, мин шул сукмагымны сагынып елармын.

# ЧЫН ШИГЫРЬГӘ ӘВЕРЕЛӘ ШАГЫЙРЬ...

*Арзанайды сүзләр. Гүя томан.*
*Гүя рәшә. Гүя күләгә.*
*Ә чын шигырь – Тукайдагы сыман –*
*Тишек үпкә белән түләнә.*

*Ком шикелле әрсез иреннәрдән*
*Нинди сүзләр шытар үлгәндә?*
*Чын шигырь ул – Җәлилдәге кебек –*
*Баш бәясе белән түләнә.*

*Учлап-учлап шигырь өләшәләр,*
*Һәрбер кулда – купшы гөлләмә.*
*Ә чын шигырь – Туфандагы сыман –*
*Сөрелүләр белән түләнә.*

*Хан йортының капкасына шакып,*
*Кемнәр үлемсезлек теләнә?*
*Чын шигырь ул – Мөдәрристәгечә –*
*Сукбай гомер белән түләнә.*

*Ялгыш кына соңгы сулыш тиеп,*
*Кәгазьдәге эзне өзгәндә,*
*Чын шигырьгә әверелә шагыйрь*
*Онытылу дигән үзәндә.*

# КИЧЕКТЕРЕЛГӘН СӘФӘР

# КИЧЕКТЕРЕЛГӘН СӘФӘР

Офыкларга уранып мин китәр идем!
Нигә алгысыта мине бу сәфәр?
Инешләргә иеләм дә юлны юрыйм –
Күрәннәре күзләремне кисәләр.

Күрәсезме, монда йөргән өрәкләр дә
Зәңгәрсу ай нурларыннан өртелгән…
Азга гына ваз кичсәм дә бу сагыштан,
Гөләпләрнең керфегенә төртеләм.

Китәр идем, дәверләргә әверелеп,
Мине алгысыткан ачык ишектән…
Ләкин җирдән баш калкыткан үлән аша
Гөрләвекләр челтерәвен ишетәм.

Чәбәләнә бер кош куак арасында,
Ни көтим мин канатланган куактан?
Дөнья минем бугазымнан кысып тотты,
Борчылма дип, шул дөньяны юатам.

Гөмбәзләргә орынып, аһ, китәр идем!
Яфрак сыман коеп кеше сүзләрен.
Тик кем сөртер дымлы иреннәре белән
Офыкларда күз яшемнең эзләрен?

# ӨМЕТ

Кулын чәбәкләп йолдыз сикерә, —
тезләнеп эзен эзлим үзәннән.
Өзелгән җаннар сиздерми генә
сүземне көтә...
Мин тик бүзәрәм.

Бүзәрәм, офык читендә болыт,
сискәнеп, җилдә кымшанган төсле.
Серле үткелгә очар алдыннан
безгә бу төштә туктап үтешле.

Чыклы үләнгә чума бер чибәр,
кочагы кемгә, кемгә ачылган? —
Ябышып калам җиләк чеменә,
пакуслар монда балга манчылган.

Ябышып калам — ызан сизелми:
үкенеч белән өмет арасы. —
Офыкка кадәр пакуслар буйлап
сабый йөгерә...
сабый...
нарасый...